Гарипова, С. Шагыйрә Зөләйха Минһаҗева рәссам һөнәрен үзләштерә / С. Гарипова. – Текст : турыдан-туры, электрон // Шәһри Чаллы. – 2026. – № 6 (30 гыйнвар). – Б. 10. – URL: https://shahrichalli.ru/news/kich-bgen-irtg/sagyira-zolaixa-minhaeva-iana-honar-uzlastera?ysclid=mlg7v11zf5684099322. – Чыгу вакыты: 28.01.2026.

# Шагыйрә Зөләйха Минһаҗева рәссам һөнәрен үзләштерә



**ТР атказанган мәдәният хезмәткәре Зөләйха Минһаҗева яңа һөнәр үзләштерә башлаган – ул майлы буяу белән картиналар иҗат итә.** Бу хакта аның белән «ВКонтакте» төркемендә уздырылган туры эфир барышында сөйләштек.

«Гомерем буе рәссамнарга сокландым, кызыктым. Көн саен үтеп йөргән урынны алар шундый итеп сүрәтли – исең китә! Алар пычрак суда да йолдызлар күрә белә. Дөрес, мин бу өлкәдә әле беренче хәрефләрен өйрәнгән бала кебек кенә. Ә барысы да Җиңү бәйрәменә әтием Мохитулланың портретын ясаудан башланды. Фотосына карап аның сурәтен төшерәм, тик катлаулы икәнен чамалыйм. Тәҗрибәле рәссам, Россия һәм Татарстан рәссамнар берлеге әгъзасы Мадьяр Хаҗиевка бардым. Ул: «Карале, шундый матур килеп чыга бу синең! Менә бу урыннарын болайрак төзәтсәң, яхшы була», – дип, канатлар куеп җибәрде. Туганнарым: «Күз карашы әткәйнекенә ошаган», – диде. Лаеклы ялга чыккач, җәйге бакча эшләре тәгәлләнгәч, бу эшкә вакыт күбрәк калды. Бүгенге көндә 12 әзер эшем бар, тик аларны әле авыз тутырып «картина» дияргә кыенсынам. Иске Чаллы урамнарын ясыйсым килә, башка темалар да кызыктыра. Яңа уй, ниндидер идея башыма килсә, төнге бердә дә торып, кулыма пумала алып, картинаны дәвам иткәнем бар», – дип уртаклашты шәһәрдәшебез.

28 январь көнне Чаллының Муса Җәлил исемендәге Үзәк китапханәсенең күргәзмәләр залында Зөләйха Минһаҗева һәм Фәридә Сәхәбиеваның картиналарыннан күргәзмә ачылды. Ул бер ай дәвамында эшләячәк.